РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«1» октябрь 2025ел г. Альметьевск № 2414

Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының «Бинаны торак урыны,
торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы
йортны авария хәлендә һәм сүтелергә
яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча
йортын торак йорт һәм торак йортны
бакча йорты дип тану буенча ведомствоара
комиссия турында» 2021 елның 12 гыйнварындагы
01 номерлы карарына үзгәрешләр кертү
турында

Кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия турында» 2021 елның 12 гыйнварындагы 01 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 октябрендәге 1506 номерлы, 2022 елның 16 маендагы 896 номерлы, 2022 елның 1 июлендәге 1328 номерлы, 2022 елның 9 ноябрендәге 2587 номерлы, 2023 елның 02 июнендәге1713 номерлы, 2023 елның 13 декабрендәге 7858 номерлы, 2024 елның 7 маендагы 1701 номерлы, 2024 елның 17 июлендәге 2429 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

комиссия составына кертергә:

Ханзафаров И.Н. - комиссия әгъзасы, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура бүлеге җитәкчесе;

Вахитов А.Р. - комиссия әгъзасы, «Үсеш департаменты» муниципаль автоном учреждениесе директоры (килешү буенча);

Нәбиуллин И.Ф. - Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Әлмәт районындагы һәм Әлмәт шәһәрендәге Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарәсе башлыгы (килешү буенча).

комиссия составыннан чыгарырга – Носова О.Г., Насыйбуллин И.Г. һәм Узаков М.К.

Зак. № 305-2000

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И.И. Сәлимгәрәевка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.М. Каюмов